**ГЛАВА**
**ФОМКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФОМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Фома ав. **КАРАР**

«29» март 2024 ел № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Нурлат муниципаль районының Фома авылы җирлегенә керүче Фома авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 08 апрелендә Фома авыл җирлеге бинасында 10 сәгать 00 минутка Фома авылы, Школьная урамы, 15 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегенең Фома авыл җирлегендә яшәүчеләргә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты белән тәэмин ителә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез элек расланган гражданнар җыенына чыгарылган сорауга үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегенең Фома торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 26.10.2023 ел, № 1 карары
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегенең Фома торак пунктында гражданнар Җыенының 26.10.2023 ел, № 2 карары,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

«2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган, һәр кешедән 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы инвентарь сатып алу; су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү);

Фома авылының урам яктырту җайланмасы;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Фома торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кышкы тоту).»

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районы рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фомкино авылындагы мәгълүмат стендларында, гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге башлыгы Р.Һ. Абдрахманов